| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

3.08.2018 Казан ш. № 10-14/кс

«Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны (механик) чистартуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару сферасындагы тарифларны дәүләт тарафыннан көйләү турында» 2013 елның 13 маендагы 406 нчы карарына, Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару сферасындагы көйләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Калдык суларны чыгаручы «Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны (механик) чистартуга тарифларны әлеге карарга теркәлгән Кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Калдык суларны чыгаручы «Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыятенә ачык булырга тиешле мәгълүматны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару сферасында мәгълүматны ачу стандартларына ярашлы рәвештә, тарифларны көйләүнең чираттагы чорына тарифларны билгеләү турында карар кабул ителгән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмый ачарга.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты карарына
кушымта 03.08.2018 № 10-14/кс

Калдык суларны чыгаручы
«Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыяте өчен
агып җыела торган суларны (механик) чистартуга тариф

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) калдык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Агып җыела торган суларны (механик) чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | |
| 1. | «Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыяте | |
| 1.1 | Башка кулланучылар (тарифлар ӨКСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 4,77 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге